**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 4 октябрендәге 4198 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 1 апрелендәге 940 номерлы «“Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” муниципаль казна учреждениесе составындагы муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогик хезмәткәрләренең һөнәри-квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы Татарстан Республикасы законының 6 статьясындагы икенче өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2024 елның 2 августындагы под-1381/24 номерлы «2022 елның 29 мартындагы под-583/22 номерлы “Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү өчен тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик тәкъдимнәр турында” әмергә үзгәрешләр кертү турында»гы әмеренә таянып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 1 апрелендәге 940 номерлы карары (Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 21 июлендәге 2335 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе составындагы муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогик хезмәткәрләренең һөнәри-квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең II бүлегендәге 2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе структурасына керә торган мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

<table>
<tr><th rowspan="2">Квалификация дәрәҗәсе</th><th rowspan="2">Вазифа атамасы</th><th colspan="3">Айга төп оклад күләме, сум</th></tr>
<tr><th>Төп гомуми белем, урта гомуми белем</th><th>Квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем</th><th>Аттестацияне уңышлы үткән затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалифика-цияләре бирү белән раслана торган югары һөнәри белем</th></tr>
<tr><td colspan="5">Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Өченче квалификация дәрәҗәсе</td><td>Методист</td><td rowspan="2">-</td><td rowspan="2">-</td><td rowspan="2">18405,0</td></tr>
<tr><td></td></tr>
<tr><td rowspan="2">Дүртенче квалификация дәрәҗәсе</td><td>Өлкән методист</td><td rowspan="2">-</td><td rowspan="2">-</td><td rowspan="2">18410,0</td></tr>
<tr><td></td></tr>
<tr><td colspan="5">Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме</td></tr>
<tr><td>Беренче</td><td>Структур бүлекчә: муниципаль</td><td>-</td><td>-</td><td>18481,0</td></tr>
</table>

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазифа атамасы** | **Айга төп оклад күләме, сум** | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **Төп гомуми белем, урта гомуми белем** | **Квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем** | **Аттестацияне уңышлы үткән затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалифика-цияләре бирү белән раслана торган югары һөнәри белем** |
| квалификация дәрәҗәсе | берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогик хезмәткәрләренең һөнәри-квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча үзенә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бүлек мөдире (башлыгы) урынбасары; структур бүлекчә: муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогик | | | 18550,0» |

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазифа атамасы** | **Айга төп оклад күләме, сум** | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **Төп гомуми белем, урта гомуми белем** | **Квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем** | **Аттестацияне уңышлы үткән затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификацияләре бирү белән раслана торган югары һөнәри белем** |
| | хезмәткәрләренең һөнәри-квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча үзенә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бүлек мөдире (башлыгы) | | | |

1.2. Нигезләмәнең V бүлегендәге 5.3.3 пунктта тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Татарстан Республикасының «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклаган һәм үстергән өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе, «Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» аерым хөрмәт билгесе, «Мактаулы остаз» аерым хөрмәт билгесе өчен өстәмә түләү күләме ике процентны тәшкил итә. Өстәмә түләү Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы мәгариф министры) әмере нигезендә билгеләнә»;

1.3. Нигезләмәгә кушымтаның «Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегендәге 1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 1.11, 1.12 пунктчалар белән тулыландырырга:

| **№ т/б** | **Мактаулы исем, бүләк атамасы** |
|---|---|
| «1.11 | Россия Федерациясенең балалар һәм яшьләрне тәрбияләү өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.12 | Мәгариф отличнигы» |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә һәм 2024 елның 1 сентябреннән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**